# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Мәгариф турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2009 елның 24 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

"Мәгариф турында" 1993 елның 19 октябрендәге 1982-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (1997 елның 2 июлендәге 1247 номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1993, № 10; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1997, № 8 – 9; 2002, №2; 2004, № 4 – 5; 2006, № 6 (1 өлеш); Ватаным Татарстан, 2009, 10 июль) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 47 статьяның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"5. Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) күрсәтелгән оешмаларда балаларын карап торткан өчен алына торган түләүнең бер өлешенә әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә компенсация алырга хокуклы.";

2) 47.1 статьяда:

а) исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"47.1 статья. **Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларында баланы тоткан өчен ата-анадан (законлы вәкилләрдән) алына торган түләү**";

б) 1 пунктта "учреждениеләрен" сүзен "оешмаларын" сүзенә, "учреждениеләрдә" сүзен "оешмаларда" сүзенә алмаштырырга;

в) 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3. Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы дәүләт һәм муниципаль мәгариф учреждениеләренә йөрүче балаларны тәрбияләүгә һәм укытуга матди ярдәм итү максатларында ата-

аналарга (законлы вәкилләргә) беренче балага компенсация – тиешле мәгариф учреждениесендә баланы карап тоткан өчен алар тарафыннан кертелгән ата-ана түләвеннән 20 процент күләмендә, икенче балага – 50 процент күләмендә, өченче балага һәм аннан соңгы балаларга күрсәтелгән ата-ана түләвеннән 70 процент күләмендә түләнә.

Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы башка мәгариф оешмаларына йөрүче балаларны тәрбияләүгә һәм укытуга матди ярдәм итү максатларында ата-аналарга (законлы вәкилләргә) беренче балага компенсация – шундый ук мәгариф оешмалары урнашкан Россия Федерациясе субъекты территориясендәге дәүләт һәм муниципаль мәгариф учреждениеләрендә баланы карап тоткан өчен ата-ана түләвенең уртача күләменнән – 20 процент күләмендә, икенче балага – 50 процент күләмендә, өченче балага һәм аннан соңгы балаларга 70 процент күләмендә түләнә.

Мәктәпкәчә белем бирүнең төп гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы дәүләт һәм муниципаль мәгариф учреждениеләрендә баланы карап тоткан өчен ата-ана түләвенең уртача күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

Компенсация алу хокукына тиешле мәгариф оешмасында баланы карап тоткан өчен ата-ана түләвен керткән ата-ананың (законлы вәкилләрнең) берсе ия була.";

3) 54 статьяның 2 пунктындагы икенче абзацында "Татарстан Республикасы шартнамәләре" сүзләрен "Татарстан Республикасы килешүләре " сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Ш. Шәймиев

Казан, Кремль
2010 елның 11 гыйнвары
№ 1-ТРЗ